| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 10 сентябре Олы Ачасыр авылы № 236

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәте реестрына кертелергә тиешле күчемле әйберләр һәм башка мөлкәт хакының иң чик күләмен раслау турында

«Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль мөлкәт реестрларын алып бару тәртибен раслау турында»гы Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2023 елның 10 октябрендәге 163н номерлы боерыгы белән расланган Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль мөлкәт реестрларын алып бару тәртибенең 2 пунктындагы 3 абзацы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Күчемле әйберләрнең (йә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәте реестрына кертелергә тиешле күчемсез әйберләргә карамаган башка мөлкәтнең) иң чик бәясен беренчел бәясе 10000,00 (ун мең) сумга тигез яисә аннан да артыграк булган мөлкәтне расларга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәте реестрына муниципаль берәмлек милкендәге кешеләр, бәясенә бәйсез рәвештә, кертелергә тиеш дип билгеләргә:

- документар кыйммәтле кәгазьләр (акцияләр) һәм документсыз кыйммәтле кәгазьләр,

- хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләре (кертемнәре) турында белешмәләр,

- күчемсез һәм (яисә) күчемле мөлкәт объектларына гомуми өлешле милек хокукындагы өлешләр турында белешмәләр.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Олы Ачасыр авыл жирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.М. Саттаров